ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 379-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 379-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 26 гыйнвары
№ 1810-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Социаль сәясәт комитеты
тарафыннан кертелә

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендәге алтынчы абзацында «укыту,» сүзеннән соң «халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм укыту» сүзләреннән соң «, халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Җәмгыятьтә санитария-гигиена культурасын һәм гражданнарда сәламәт яшәү рәвешенә мотивация булдыру максатларында халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту үткәрелә, ул сәламәт яшәү рәвешен, дөрес туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, булдыру, авыруларны профилактикалау, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен кирәкле булган белемнәрне, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүнең башка мәсьәләләре буенча белемнәрне, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәреннән, басма продукцияләрдән (белешмәләр, буклетлар, плакатлар һәм башкалар), социаль рекламадан файдаланып, шулай ук оештырылган коллективларда чаралар үткәргәндә, гражданнарга индивидуаль консультацияләр биргәндә, тарату юлы белән гамәлгә ашырыла.

Халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту тәртибе, шартлары һәм рәвешләре һәм аны тикшереп тору тәртибе мәгариф турында законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Татарстан Республикасы законы проекты «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 ноябрендәге 429-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Профилактик чараларны хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләренә халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту чараларын үткәрү хокукын өстәү тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасында халыкны санитария-гигиена ягыннан агартуда катнашу вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек салу өлкәсендә вәкаләтле органына бирелгән («Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьялары). Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының халыкны санитария-гигиена ягыннан агартуда катнашуы «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләрен турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән, шуңа бәйле рәвештә әлеге Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.